**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2022елның 31 гыйнвары** **16-РС номер**

# КАРАР

## «2019-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе турында» 2019 елның 14 октябрендәге 74-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «2019-2021елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Лаеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе» 7 нче таблицаның «Мәдәниятне һәм тризмны үстерү» бүлегендәге 14 бүлекчәсен, кушымта нигезендә, яңа редакциядә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Район башлыгы-муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Советының «31» гыйнварындагы
16-РС номерлы карарына кушымта

**Лаеш муниципаль районында инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау**
**ТӘРТИБЕ**

| **Мәдәният һәм туризм үсеше** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 14 | Туризмның төрле төрләре өчен, шул исәптән Кама елгасы яры (Кама диңгезе Пляж), «Семрук» кино-авылы тирәсендәге территория, Экстрим-парк һәм башкалар өчен әзер инфраструктуралар булдыру. | 2022-2030 | ЛМР Башкарма комитеты, ТР Туризм буенча комитеты, инвестицион үсеш агентлыгы, табигать территорияләрен һәм экотуризмны үстерү дирекциясе һәм башкалар, | - | - |